МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

28.09.2020 г.Казань № 680

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 20 октябрендә 6887 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән (10.08.2016 ел № 465, 14.05.2018 ел № 363, 10.10.2018 ел № 935, 22.01.2019 ел № 45, 03.04.2019 ел № 226, 05.08.2019 ел № 595, 23.10.2019 ел № 888, 14.07.2020 ел №514 боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына китерелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Министр вазыйфасын башкаручы Э.А. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 28 сентябрендәге 680 номерлы боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы
Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 16 июлендәге 473 номерлы «Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы пенсионерларының аерым категорияләрен ташламалы шартларда шифаханә-курорт дәвалавына юллама алу өчен исәпкә кую буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелгән үзгәрешләр

2.6 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек каналлары буенча түбәндәгеләр кабул ителә:

шәхси исәп-хисап счетының иминият саны (СНИЛС) турында белешмәләр (Россия Федерациясе Пенсия фондыннан);

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;

гариза бирүченең гаилә составы турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;

Россия Федерациясе Пенсия фондында, Федераль салым хезмәте буенча булган керемнәр турында белешмәләр;

күчемсез милек булуы турында белешмәләр (Росреестрдан);

транспорт чараларының, үзйөрешле транспорт чараларының һәм башка төр техниканың (вәкаләтле оешмалардан) булуы турында белешмәләр;

торак урынны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану (вәкаләтле оешмалардан) турында белешмәләр;

шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында белешмәләр (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) (вәкаләтле оешмалардан).

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына (вәкаләтле оешмалардан) салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.

Гариза бирүче югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

Күрсәтелгән белешмәләр гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры вәкаләтле оешмалардан, шул исәптән электрон рәвештә алынырга мөмкин.

Идарә (бүлек) гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итәргә хокуклы түгел:

дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яисә аларны гамәлгә ашыру каралмаган гамәлләрне гамәлгә ашыру өчен документлар һәм мәгълүмат бирүне;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм (яисә) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә күрсәтелгән документлардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмалар карамагында булган дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен түләү кертүне раслаучы документлар һәм мәгълүмат бирүне;

210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, беренче тапкыр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартканда яисә дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартканда документларның һәм мәгълүматның булмавы һәм (яисә) дөреслеге күрсәтелмәгән документлар һәм мәгълүмат тапшыруны.»;

Гариза бирүче күрсәтергә хокуклы булган документларны алу ысуллары һәм бирү тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында билгеләнгән.

Гариза бирүченең югарыда күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез була алмый

2.8 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган.

Юллама алу өчен хисапка куюдан баш тарту өчен нигез булып тора:

1. Гариза бирүченең әлеге регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмавы яки тулы булмаган пакетын тапшыруы;

2. Вакыты гамәлдән чыккан документларны тапшыру;

3. Гариза бирүченең уртача айлык кереме зурлыгының Татарстан Республикасында пенсионерның яшәү минимумы итеп билгеләнгән күләмнән 400 процентка артуы;

4. 2004 елның 8 декабрендәге 63-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законына кушымтаның «а»-«г», «е», «ж» пунктларында һәм ТР МК 97 номерлы карары белән расланган Тәртипнең 1.2 пунктындагы икенче һәм өченче абзацлары нигезләмәләрендә билгеләнгән гаиләнең (гражданның) мөлкәти тәэмин ителеш дәрәҗәсеннән гариза бирүченең өстен булу;

5. Гражданның Татарстан Республикасы чикләреннән чыгып китүе;

6. Гражданның Россия Федерациясе норматив хокукый актлары нигезендә шифаханә-курорт дәвалавына хокукы булган халык категорияләренә каравы

7. Гражданның Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычы булуы. »;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле җиһаз, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналар һәм корылмаларда гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат мөрәҗәгать итүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла. Көтү залларында (биналарда) әлеге Регламентның 1.4.2 пунктындагы 1 пунктчасында каралган белешмәләр, шулай ук аларны тутыру үрнәкләре белән дәүләт хезмәте күрсәтү турында гарызнамә формалары урнаштырылган мәгълүмати стендлар җиһазландырыла.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтелгән объектлардан (алга таба – объект) файдалану өчен инвалидларга түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) объектларга тоткарлыксыз керү һәм алардан чыгу мөмкинлеге;

б) дәүләт хезмәте күрсәтү урынына керү максатларында объект территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтүче объектның хезмәткәрләре, ассистив һәм ярдәмче технологияләр, шулай ук алмаштырылган кресло-коляска ярдәмендә;

в) объектка кергәндә транспорт чарасына утыру һәм төшү мөмкинлеге, шул исәптән кресло-коляска файдаланып һәм, кирәк булганда, объектның хезмәткәрләре ярдәмендә;

г) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функцияләре тотрыклы бозык булган инвалидларны объект территориясе буенча озата бару;

д) объектка кергәндә һәм аннан чыкканда инвалидка ярдәм итү, инвалидка җәмәгать транспортының мөмкин булган маршрутлары турында мәгълүмат бирү;

е) инвалидларның объектка һәм дәүләт хезмәте күрсәтүләргә каршылыксыз керүен тәэмин итү өчен кирәкле мәгълүматны аларның тормыш эшчәнлеге чикләнүен исәпкә алып урнаштыру, шул исәптән дәүләт хезмәтләрен алу өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язу, билге һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны контрастлы яссылыкта башкарылган Брайльнең рельефлы-нокталы шрифтындагы тамгалар белән кабатлау;

ж) махсус укытылуын раслый торган, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386 номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә бирелгән документ булган очракта, объектка озата баручы этләр белән кертелүне тәэмин итү.

Законнарда һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр нигезендә инвалидларга дәүләт хезмәтләреннән файдалану өчен түбәндәге шартлар тудыру тәэмин ителә:

а) инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтү кагыйдәләре турында, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү турында, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка гамәлләрне башкару турында үзләре өчен аңлаешлы формада мәгълүмат алу өчен кирәкле ярдәм күрсәтү;

б) ишетү буенча инвалидларга, кирәк булганда, рус ым-ишарә телен кулланып дәүләт хезмәте күрсәтү, шул исәптән объектка сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертүне тәэмин итү;

в) инвалидларга башка затлар белән бертигез рәвештә дәүләт хезмәтен алырга комачаулаучы каршылыкларны җиңүдә башка төрле ярдәмне күрсәтү;

г) дәүләт хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы документ, белдерү һәм күрсәтмәләрнең (шул исәптән мәгълүмати стендта) рельефлы-нокталы Брайль шрифтында һәм контрастлы фонда башкарылган күчермәләренең, шулай ук теркәү бүлегендә аудиоконтурының булуы.

Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә реконструкцияләнгән, яңартылган объектларга һәм чараларга карата кулланыла»;

«Дәүләт хезмәтен яисә таләпне билгели торган норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» Федераль законның 14 ст., 15 ст»;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 30 июлендәге 527 номерлы «Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау өлкәсендә объектларның һәм күрсәтелә торган хезмәтләрдән инвалидларның файдалану шартларын тәэмин итү, шулай ук аларга кирәкле ярдәм күрсәтү тәртибен раслау турында» боерыгы;

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Идарә (бүлек) белгече түбәндәге мәгълүматларны үз эченә алган документларны электрон рәвештә ала:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» (Россия Федерациясе Пенсия Фондыннан) федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмалардан);

Россия Федерациясе Пенсия фондында, Федераль салым хезмәте буенча булган керемнәр турында белешмәләр;

күчемсез милек булуы турында белешмәләр (Росреестрдан);

транспорт чараларының, үзйөрешле транспорт чараларының һәм башка төр техниканың (вәкаләтле оешмалардан) булуы турында;

торак урынны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану (вәкаләтле оешмалардан) турында белешмәләр;

- шәхси исәп-хисап счетының иминият саны турында

шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында белешмәләр (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) (вәкаләтле оешмалардан).

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына (вәкаләтле оешмалардан) салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.

3.4.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.2. Идарәдә (бүлектә) ташламалы шартлард шифаханә-курорт дәвалануын юллам алу өчны исәпкә кует (куюдано баш тарту) турынд карар кабул

итү өчен кирәкл белешмәләр булмаган очракта, Идарә (бүльки) белгечи, шул исәптән электрон рәвештә ведомствоара электрон хезмәттәшльки системасы аши, белешмәләр бирү турынд запрослар җибәрә:

«Иминият пенсияләре турында», «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» һәм «Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында» (Россия Федерациясе Пенсия Фондына) федераль законнар нигезендә пенсия билгеләү турында вәкаләтле оешмалардан белешмәләр;

мөрәҗәгать итүченең гаилә составы турында (вәкаләтле оешмаларга);

Россия Федерациясе Пенсия фондында, Федераль салым хезмәте буенча булган керемнәр турында белешмәләр;

күчемсез милек булуы турында белешмәләр (Росреестрдан);

транспорт чараларының, үзйөрешле транспорт чараларының һәм башка төр техниканың (вәкаләтле оешмаларга) булуы турында;

торак урынны билгеләнгән тәртиптә яшәү өчен яраксыз дип тану (вәкаләтле оешмаларга) турында;

Россия Федерациясе Пенсия фондына шәхси исәп-хисап счетының иминият саны турында

шифаханә-курорт дәвалавына медицина күрсәткечләре булу турында белешмәләр (мәгълүмати хезмәттәшлек кертелгәннән соң) (вәкаләтле оешмаларга).

Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына (вәкаләтле оешмаларга салымнар, җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча бурыч булмау турында белешмәләр.

Ведомствоара гарызнамә электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә ведомство электрон хезмәттәшлек системасы каналлары буенча (алга таба - СМЭВ) төзелә һәм җибәрелә.

Ведомствоара гаризаны СМЭВ каналлары буенча электронный документ формасында формалаштыруның техник мөмкинлеге һәм юнәлешләре булмаганда, ведомствоара гарызитнамә кәгазьдә почта аша, бер үк вакытта почта аша яисә курьер аша.

Ведомствоара гарызнамә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7.2 статьясы таләпләре нигезендә төзелә.

3.4.1 һәм 3.4.2 пунктлары белән билгеләнә торган процедуралар гариза һәм документларны кабул итү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: ведомствоара гарызнамә юнәлеше. »;

3.4.3 пунктында «икенче-унынчы» сүзләрен «икенче-унберенче» сүзләренә алмаштырырга;

3.6 пунктындагы дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гариза алдагы процедураны тәмамлаган көндә гамәлгә ашырыла.